Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN

УНИВЕРСИТЕТ

№ 3 (3)

20 октябрь 2011 ел

## • Ике авыз сүз

17 октябрь көнне КФУ ректоры Илшат Гафуров җитәкчелегендә ректорат утырышы булды. Бу юлы ул Казан федераль университетының үсеш программасы турындагы киңәшмә белән берләштерелгән иде. Башта Илшат Рәфкать улы институтлар һәм бүлек җитәкчеләренә университет биналарында җылылыкның вакытында бирелүен контрольдә тотарга кушты. Икътисад һәм финанс институты, шулай ук Территориаль үсеш һәм идарә итү институтларының яңа директорлары – Шамил Мәхмүт улы Вәлитов һәм Наилә Гомәр кызы Баһаветдинова белән таныштырды.

Укыту-методик идарә җитәкчесе О.Тимофеева КФУда белем алучылар контингентының регламент хәрәкәте белән таныштырды. Ул 1995 елдан бирле бер дә үзгәртелмәгән иде, шунлыктан кайбер төзәтүләр кертергә туры килде. Регламентта КФУ студентларын күчерү, яңадан укый башлау, укудан чыгару тәртипләре язылган. Кайбер юнәлешләрне камилләштерү шарты белән, регламент кабул ителде.

Уку-укыту эшчәнлеге буенча проректор Р.Минзарипов уку-укыту эшчәнлеге белән идарә итү структурасының проектын тәкъдим итте. Анда укыту-методик идарә һәм белем бирү департаменты керер дип планлаштырыла. Чыгышны тыңлаганнан соң, ректор барлык функцияләрне дә җентекләп билгеләргә һәм структураны эшләп бетерергә кушты.

Финанс эшләре буенча проректор Р.Муллакаева исә КФУның финанс эшчәнлеге буенча идарә органнарын оештыру структурасы белән таныштырды. Ул эчке аудит идарәсеннән, нормалаштыру һәм идарә учетының бюджет департаменты, түләүне җайга салу һәм казначейство, хисап бирү һәм исәпкә алу бухгалтериясе департаментыннан торачак. Саналганнарның беренче икесе – өр-яңа юнәлешләр. «Бу блокларны булдыру барлык университет финанс системасын контрольдә тоту һәм тәртипкә салу ихтыяҗыннан чыгып эшләнде», – дип билгеләп үтте Рәйсә Риф кызы. Финанс блогының оештыру структурасын оптимальләштерү нәтиҗәсендә, 28,85 ставка бушый. Бу исә бюджет чыгымнарын сизелерлек экономияләүгә китерә. Шулай итеп, утырышта финанс эшчәнлеге идарә органнарының вакытлыча структурасы расланды.

Иҗтимагый һәм тәрбия эшләре буенча проректор А.Межведилов 23 октябрь көнне КФУ галим-мөгаллимнәре һәм хезмәткәрләре белән берлектә үтәчәк, спортның 9 төреннән торган «Сәламәт бул» Спартакиадасында актив катнашуны үтенде.

• • • •

Күптән түгел Ланчано (Италия) шәһәрендә баянчы-аккордионистларның XX Халыкара конкурсы булып узды. Анда Казан баянчысы – КФУ профессоры Владимир Федотов зур җиңү яулады. Ул, оркестрга кушылып, А.Пьяццоллының үзе эшкәрткән «Либертанго»сын һәм В.Зубицкийның «Мин сине яратам, Пезаро» дигән джаз пьесасын башкара. Нәтиҗәдә, Халыкара жюри берсүзсез иң югары бүләк – Гран-прины (абсолют) Владимир Федотовка тапшыра. I һәм II премия беркемгә дә бирелми, ә III урынга Брно (Чехия) һәм Санкт-Петербург музыкантлары лаек була. Фенароли театрында узган фестиваль концертында солист буларак В.Федотовның «Гармония» оркестрына кушылып уйнавыннан соң, публика артистларны озак кына сәхнәдән төшермичә кул чаба. Халыкара конкурс президенты В.Зубицкий: «В.Федотовның чыгышы халыкка бик ошады. Аның өчен шатбыз. Италия вәкилләренең минем яныма килеп соклануларын җиткерүе – зур мәртәбә», – дип белдерде.

• • • •

20-22 октябрь көннәрендә университетта «Хәзерге Россиядә мәгълүмати кыр: гамәлләр һәм эффектлар» дип аталган VIII Халыкара фәнни-гамәли конференция уза. Чара Журналистлар берлеге белән берлектә КФУның журналистика һәм социология факультеты нигезендә оештырыла.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



# Галимнәр җыены

2011 елның 21-24 октябрь көннәрендә Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында «Төрки телләр диалектологиясе, тарихы һәм грамматик төзелеше» дип аталган Халыкара тюркологик конференция уза.

Галимнәр форумы татар теленең грамматик төзелешен һәм аның диалектларын өйрәнүдә фәнни мәктәп булдырган, Россия төрки тел белеменең үсеше тарихында якты эз калдырган профессор, филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Диләрә Гариф кызы Тумашеваның (1926-2006) якты истәлегенә багышлана, Татарстан Республикасының Министрлар кабинеты һәм Фәннәр академиясе белән берлектә оештырыла.

Конференция эшендә Берләшкән дәүләтләр бердәмлеге һәм Төркия, Кытай, Болгария, Венгрия, Казакъстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Украина кебек чит илләрдән, шулай ук Россиянең Башкортстан, Чувашия, Пермь, Төмән һәм Татарстан төбәкләреннән барлыгы 175 галим катнаша.

Халыкара конференция эшендә Д.Тумашеваның фәнни мирасы барлана, диалектология һәм төрки телләрне өйрәнүдәге яңа эзләнүләр, чагыштырма-тарихи төрки тел белеме һәм алтаистика фәнендәге юнәлешләр билгеләнә, төрки лексикология һәм лексикографиянең көнүзәк мәсьәләләре ачыклана, төрки халыклар әдәбияты һәм мәдәниятенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге яктыртыла. Фәнни форумда Россия һәм чит илләрдә төрки телләргә өйрәтүнең торышына да зур игътибар бирелә.

*Рәсемдә: университет галимнәре, 1978 ел*

## • Яңа ачыш

# Ашлы шәһәре серләре

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Казан археологлары Идел буе Болгарстанының тагын бер борынгы шәһәр калдыкларына тап булды.

Ульян өлкәсендә җирле археологлар Казан федераль университеты геофизиклары белән бергә Алейкино авылы янындагы территорияне тикшерә башладылар. XI гасырда биредә Идел буе Болгарстанының зур шәһәре урнашкан булган. Археологлар әйтүенчә, борынгы шәһәр 180 гектар җирне биләп торган. Якынча 90 меңләп кеше яшәгән. Киевтән дә зуррак булган. Шәһәрнең исеме әле төгәл билгеле түгел, Ашлы булырга мөмкин дигән фараз бар. Ул елъязмаларда телгә алына.

Ашлы зурлыгы буенча дәүләтнең Болгар һәм Биләр шәһәрләреннән соң өченче урынны алып торган. Ашлы Татарстан территориясенә кергән дигән фикерләр дә бар.

**Ахыры 2нче биттә.**



ulyanovsk.russiaregionpress.ru

**Илшат ГАФУРОВ**,
Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры



***Хөрмәтле конференциядә катнашучылар, хезмәттәшләр!***

*Татар теленең грамматик төзелешен һәм аның диалектларын өйрәнүдә үз фәнни мәктәбен булдырган галимә, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе Диләрә Гариф кызы Тумашева, үз туган халкына фидакарьләрчә хезмәт итеп, исемен ил йөрәгенә язды.*

*Диләрә Гарифовна тормыш юлының иң бай һәм нәтиҗәле чоры Казан дәүләт университетында эшләгән елларга туры килә. Мәскәү университетында дөньякүләм танылган атаклы тюркологлар Н.К.Дмитриев, Э.В.Севортян, В.Н.Насилов, Ә.Н.Нәҗип һәм башкалардан ул фундаменталь филологик белем ала, Н.К.Дмитриев җитәкчелегендә кандидатлык диссертациясе яклап, 1952 елның азагында Казан университетына килә һәм остазларының традицияләрен дәвам иттереп, татар тел белеменең тармакларын киңәйтеп, аның яңарышына иреште.*

*Диләрә Гариф кызы Тумашева озак еллар университетның тарих-филология факультетында декан, бер үк вакытта 25 ел дәвамында татар теле кафедрасы мөдире булып эшли. Тынгысыз җанлы, гаять дәрәҗәдә җаваплы, принципиаль профессор Тумашева, декан буларак, факультетның гыйльми-фәнни эшчәнлеген һәм тәрбия, уку-укыту системасын камилләштерүгә зур көч куя. Казан Императоруниверситетында дан тоткан Көнчыгыш бүлеге традицияләрен яңадан кайтарып, аны төрки һәм көнчыгыш телләрен өйрәнүнең үзәгенә әйләндерү максатыннан оештырылган Шәрекъ институтын торгызуда аның өлеше зур. Диләрә Гариф кызы көнчыгыш телләре кафедрасын биш ел җитәкли һәм шушы юнәлештә югары квалификацияле фәнни-педагогик кадрлар әзерләүдә актив катнаша.*

*Татар филологиясендә беренче хатын-кыз фән докторы, профессор, Казан университетының иң беренче хатын-кыз деканы, татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булып академик дәрәҗәсенә ирешкән Диләрә Гариф кызы Тумашева фәнни мәктәбен бүгенге көндә егерме бер фән кандидаты, шуларның тугызы фән докторы һәм профессорлар дәвам итә.*

*Татар халкының затлы галиме, гомере буе татар халкына хезмәт иткән Диләрә Гариф кызы Тумашева хөрмәтенә багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция эшендә уңышлар һәм күпкырлы гыйльми-тикшеренү өлкәсендә яңа ачышлар телим.*

**Зилә ВӘЛИЕВА,**
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары



***Хөрмәтле галимнәребез, конференция кунаклары һәм студентлар!***

*Татар халкына борынгыдан килгән гүзәл бер традиция хас: ул остазга тугрылык һәм хөрмәт. Безнең гуманитар фәнебездә якты маяк булып янган олуг һәм хөрмәтле остазларыбыз бар. Алар – профессорлар Латыйф Җәләй, Мөхәммәт Гайнуллин, Хатыйп Госман, Мансур Хәсәнов. Тел гыйлемендә бүген дә алар мәсләген дәвам итүче – академик Мирфатыйх Зәкиев.*

*Академик Диләрә Тумашева шушы йолдызлыкта аерым бер урын тота. Ул фәнни мирасы, берничә зур тармакка юнәлеш бирүе һәм аларның фәнни югарылыгы белән зур бер мәктәп хасил итә. Мәскәү университетының күренекле тюркологгалимнәре Николай Дмитриев, Эрванд Севортян, Әмир Нәҗип кебек корифейлар мәктәбен узып килгән татар галимәсе үзе тикшергән ике өлкәгә – морфология һәм диалектологиягә – академик төсмер бирде. Татар теленең зур һәм катлаулы бер диалекты булган Көнчыгыш диалектын, аның барлык эре сөйләшләрен ул җентекләп өйрәнде, зур, саллы хезмәтләр бастырды. Аның бу эшчәнлеге Рәсәй фәнендә һәм дөнья тюркологиясендә югары бәя алды. Безнең бөек галимәбезнең бәрәкәтле мирасы бүген дә татар тел гыйлеменең академик югарылыгын билгели.*

*Тел гыйлемендә аның мәктәбен дәвам итүчеләр мәдәниятебезнең төрле өлкәләрендә: мәгарифтә, нәшриятта, әдәбиятта, матбугатта эшли. Галимәнең шәкертләре, фән өлкәсендә дә мөһим ачышлары белән танылып, үз юнәлешләрен булдырдылар һәм дәвамчыларын үстерәләр.*

*Бүгенге халыкара конференциядә Татарстанда, тугандаш республикаларда һәм чит илләрдә телләрне саклау, үстерү һәм аларны өйрәнү алымнарын камилләштерү юллары карала. Диләрә Гарифовнаның фәнни хезмәтләре үз чорында ук бүгенге көн таләпләренә һәм казанышларына туры килерлек иде. Ә инде хәзерге заманның яңа технологияләре аларны гамәли кулланырга мөмкинлек бирә.*

*Әлеге конференция республиканың фәнни тормышына зур структур һәм концептуаль яңалыклар алып килгән федераль университет базасында уза. Конференция, күренекле галимәбезнең мирасын барлап, телләрне өйрәнүдә бәрәкәтле яңа ысуллар эзләп, филологик, гуманитар фәннәр үсешенә яңа сулыш өрүен һәм бу җаваплы өлкәдә галимнәргә, практикларга – тел укытучыларына зур этәргеч булуын телим. Конференция эшендә уңышлар, ә барлык катнашучыларга остазларына лаеклы фәнни казанышлар юлдаш булсын иде!*

• Яңа ачыш

## Ашлы шәһәре серләре

*Башы 1нче биттә.*

Археология фәнендә әлеге тарихи урын Иске Алейкино шәһәре буларак билгеле. XIX гасырның кайбер язмаларында шәһәр атамасы телгә алына. Ләкин беренче археологик эзләнү эшләре XX гасырның 90нчы елларында гына башлана. Казан университеты геофизикларын таш архитектура калдыклары кызыксындыра. Борынгы шәһәрдә мәчет, кремль, тимер кою һәм чүлмәк ясау остаханәләре дә булырга мөмкин. Хәзер биредә фермерларның авыл хуҗалыгы биләмәләре урнашкан.

Кызганычка каршы, тарихи һәйкәл күп кыйммәтләрне, бай хәзинәләрне югалтырга өлгергән. Монда «кара археологлар»ның өлеше зур.

Ульян өлкәсе археологлары, Казан университеты геофизиклары үткәнне кире кайтару өчен бар көчләрен куя. Изге урын киләчәктә тарихи-мәдәни һәйкәл дәрәҗәсен алырга мөмкин. Нәтиҗәдә, биредә археологик тыюлык барлыкка киләчәк.

Җирле халык еш кына керамика һәм металл корылмаларының калдыкларына тап булган.

Идел буе Болгарстаны – X-XIII гасырларда гөрләп торган дәүләтләрнең берсе. Ул урта Идел буе һәм Чулман бассейны янында урнашкан булган. Болгарстанның төп тарихи урыннары хәзерге Татарстан, Самара, Пенза, Ульян һәм Чувашия территориясендә урнашкан. Бүгенге көндә ике меңнән артык Болгар һәйкәле билгеле. Алар арасында 190 шәһәр һәм 900дән артык авыл бар. Бу турыда борынгыдан сакланып калган корылмалар сөйли.

# Себер төрки мәктәбенә нигез салучы

**Хәнисә АЛИШИНА,**
Төмән дәүләт университеты профессоры

Диләрә Гариф кызы бәхетле һәм лаеклы гомер кичерде. Ул 1926 елның җәендә Төмән шәһәрендә туа. Әнисе, Әминә ханым Галләмова, Пермь татарларының күренекле нәселеннән, заманында Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлый. Төмәнөлкәсенең Урманбаш, Талмы, Малчын авылларында татар теле укыта. Кечкенә Диләрә бишенче сыйныфта укыганда, әнисе, бакый дөньяга күчә. Әтисе Гариф абый Җаббаров нәселе Арча районының Наласа авылыннан. Аның ата-бабалары атаклы купец – Колокольниковлар (Казандагы сабын заводы белән дә сәүдә элемтәләре тотканнар) чакыруы буенча Төмәнгә күченеп килгән булалар. Гариф абый гади эшчедән Төмән һөнәр училищесы директоры дәрәҗәсенә ирешә.

1934-1944 елларда Диләрә Җаббарова Төмәннең 21нче мәктәбен алтын медальгә бетерә. 1949 елны Мәскәү шәһәрендә М.В.Ломоносов исемендәге университетны тәмамлый һәм филолог-тюрколог белгечлеге ала. Диләрә Гарифовна үзенең истәлекләрендә педагоглары Бенциан Меерович Гранде, Борис Всеволодович Севортян, Мәдинә Искәндәр кызы Богдановаларны бик җылы искә ала. Фәнни җитәкчесе – Мәскәү тюркологлар мәктәбен нигезләүче, СССР Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, профессор Н.К.Дмитриев тырыш, булдыклы укучысына аспирантурада укуын дәвам итәргә тәкъдим ясый. 1952 елны «Себердә (Төмәндә) татар диалектлары» дигән темага диссертация яклый. Озакламый Диләрә Гарифовна ире Равил Тумашев белән Казанга күченә. Аның галимлек тормышы шуннан башлана. 50 ел буена ул Казан университетында эшли. Биредә докторлык диссертациясен яза. 1969 елда филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә бирелә. Диләрә Тумашева Казан, Татарстан, Россия, СССРда гына түгел, чит илләрдә дә билгеле һәм хөрмәтле шәхес.

Диләрә Гарифовна – үз фәнни мәктәбен булдырган галимә. Аның җитәкчелегендә яклаган 21 фән кандидаты, 7 фән докторы бар. Алар ТР Фәннәр академиясенең төрле институтларында, Казан, Томск, Төмән дәүләт университетларында, Казан, Алабуга, Яр Чаллы, Абакан уку йортларында эшлиләр.



Минем остазым һәм фәнни җитәкчем бик юмарт һәм киң күңелле, сизгер кеше иде. Безнең танышуга 25 ел узган. Диләрә Тумашева укучылары арасында иң бәхетлесе мин булганмындыр, мөгаен. Төмәндә туып, 18 ел гомере шунда узгангамы, ул елга бер мәртәбә булса да туган шәһәренә кайтып килә иде. Без аның белән җанына кадерле булган урыннарда, урамнарда йөри идек. Туган шәһәренә булган яратуы миңа да күчеп калды. Шундый сәяхәтләрнең берсендә ул миңа: «Кеше сау-сәламәт һәм ныклы тылы булганда гына фәнгә тулаем хезмәт итә ала», – дип әйткән иде. Диләрә Гариф кызының ныклы тылы – аның ире, Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты – Равил Тумашев булды. Ул аны: «Минем Диләрәм... алтыным минем... тормыш юлдашым», – дип йөртә иде. Үзебездә «Тумашева укулары»н әзерләп йөргәндә, без Равил абыйдан истәлекләре белән уртаклашуын үтендек. Ул хат язып җибәрде. Хатын менә болай тәмамлаган иде: «Язмамның ахырында тагын бер кат искәртәсем килә: менә нинди җиңүләргә иреште минем Диләрәм! Рәхмәт аңа, алтыныма минем. Алтын туебызны әлләни зурлап үткәрмәсәк тә, аның җиңүен, аның юбилеен бәйрәм итәбез! Дан аңа!»

Казан университеты аспирантурасында укыган елларымда Диләрә Гариф кызыннан өйрәнгәннәремне үземнең укучыларыма тапшырырга тырышам. Без 20 ел дус булганбыз. Минем җанымда аңа карата иң якты һәм иң яхшы истәлекләр генә калды, үземнең җиңүләрем, казанышларым белән мин аңа бурычлы. Ул минем өчен татар хатыны, чын кеше, галимә, фәнни җитәкче, педагог эталоны булды һәм булачак. Гомеренең соңгы елларында язган хатыннан өзек: «...Үзем турында да языйм әле. Бик арыйм. Ел ахырында татар телендә язылган коллектив монографияне тапшырдык. Мин – җитәкче һәм шул ук вакытта «Фигыльнең лексик һәм лексик-грамматик мәгънәсе» һәм «Модальлек, темпоральлек, персональлекнең функциональ-семантик категорияләре» дигән ике бүлекне үзем яздым – 150 битлек компьютер тексты...»

Диләрә Гариф кызына рәхмәтем чиксез. Ул башлаган, үзенең гомерен багышлаган эш бүген дә дәвам итә...

■ *Хәнисә Алишина остазы Диләрә Тумашева белән*



■ *Диләрә Тумашева якташлары белән*

■ *Фотолар автор архивыннан алынды*

# Элеккеге Верный – хәзер Алматы

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Көз аеның ягымлы сентябрь ахырларында Казакъстан Җөмһүриятенең Алматы шәһәрендә дәүләт бәйсезлегенә – 20, Мохтар Ауэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институтының төзелүенә 50 ел тулуга багышланган халыкара гыйльми-теоретик конференция үткәрелде.

Бу зур тантаналы чарада институтның директоры, күренекле галим Сәйт әфәнде Каскабасов чакыруы буенча Татарстаннан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, профессор Ким Миңнуллин һәм Казан федераль университеты профессоры Хатыйп Миңнегулов катнашты. Конференциягә Казакъстанның үз галимнәре, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Мисыр, Төркия, Үзбәкстан, Кыргызстан һәм кайбер башка илләрнең вәкилләре дә чакырылган иде.

«Өч көн дәвамында әдәбият фәненең, сәнгатьнең, фольклористиканың мөһим мәсьәләләре тикшерелде», – дип сүзен башлады Хатыйп ага. Пленар утырышта Ким Миңнуллин Татарстан галимнәренең котлау-теләкләрен җиткерә, казакъ-татар бәйләнешлары турында сөйли, ә Хатыйп Миңнегулов Җучи Олысының тарихы һәм әдәбияты турында чыгыш ясый.



Рәсемдә (сулдан уңга): профессорлар К.Миңнуллин, Ф.Хисаметдинова, Х.Миңнегулов.

Конференция кысаларында башка төрле чаралар да үткәрелгән. «Мәгълүм булганча, Мохтар Ауэзов (1897-1961) – казакъ әдәбиятында гына түгел, ә Советлар берлеге сүз сәнгатенең дә күренекле вәкиле, академик, җәмәгать эшлеклесе. Аның Абай турындагы 4 томлык роман-эпопеясе дөньяның 50дән артык теленә тәрҗемә ителгән. Кечкенә вакытта ул Семипалат каласының татар мәдрәсәсендә дә белем ала, татар кешеләре, зыялылары белән аралашып тора. М.Җәлилгә Ленин премиясе бирүдә актив катнаша. Бераз вакыт Фатыйма исемле татар ханымы белән дә яшәп ала. Уллары Морад Ауэзов (1943 елгы) – күренекле галим. Аның белән дә аралашып алдык. Конференциядә катнашучылар киң җәмәгатьчелек белән бергә М.Ауэзов һәйкәленә чәчәкләр куеп, аның музей-йортында да булдык, – дип сүзен дәвам итте Хатыйп ага. – Хәзерге Алматы 1921 елга кадәр Верный исемен йөртә. Ул вакытта әле аның халкы 45 мең тирәсе генә була. 1929 елда бу шәһәр Казакъстанның башкаласына әверелә (аңа кадәр җөмһүриятнең мәркәзе Оренбург, аннан Кызыл Орда була). Гадәттә, башкалалар тиз үсә. Алматы да чыгарма түгел. Моны анда яшәүчеләр саны да ачык күрсәтә: 1933 елда – 168 мең, 1938 елда – 270 мең, 1966 елда – 600 мең, 1981 елда – 1 млн. Хәзер исә аның халкы 2 млн. якынаеп килә».

Әдәбият һәм сәнгать институты М.Ауэзовның 50 томлык академик басмасын әзерләп чыгарган. Шул көннәрдә китапларны тәкъдим итү кичәсе дә үткәрелә. Гомумән, казакъ халкының бөек әдибе хәзер дә җәмәгатьчелекнең, галимнәрнең игътибар үзәгендә. Махсус мәкалә-хезмәтләр дә чыгып тора икән. Аларда Ауэзовлар нәселенең Мөхәммәд пәйгамбәр һәм Әхмәд Ясәви белән бәйләнешле булуы да ассызыклана (М.Ауэзов. Об отце и его потомках // Новое поколение (Республиканская газета), 27.09.2011).

«Алматыда өч кенә көн торсак та, анда күргән, ишеткән, кичергәннәребез шактый күп һәм мул булды, зиһеннәребезне баетты. Казакъстанның бу матур каласына, аның халкына хөрмәт-ихтирамнарыбызны тагын да арттырды», – диде Хатыйп Миңнегулов, сәяхәтләре турындагы әңгәмәне йомгаклап.

# Күренекле тюрколог

**Фәһимә ХИСАМОВА,**
КФУ профессоры

Татарстан Республикасының Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, РФ һәм ТРның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор Диләрә Тумашева - үзеннән соң зур фәнни мирас калдырган талантлы галимә.



Аның ярты гасырлык фәнни эшчәнлеге татар тел белемендә генә түгел, ә барлык тюркология фәнендә билгеле.

XX гасырның икенче яртысында татар тел белемен академик Д.Тумашеваның фәнни һәм фәнни-оештыру эшчәнлегеннән башка күз алдына китереп булмый. Ул К.Насыйри, Җ.Вәлиди, Г.Алпаров, В.Хангильдин h.б. атаклы галим-филологлар категориясенә керә. Академик Тумашева үзенең укытучылары – күренекле тюркологлар – Н.К.Дмитриева, Э.В.Севортян, Ә.Н.Нәҗипләрнең лаеклы дәвамчысы булды. Студент чагында ук Д.Тумашева остазы Н.К.Дмитриев киңәше белән, тюркологиянең бер тармагы буларак, Себер татарларының телен өйрәнүне сайлый. «Көнчыгыш Себер татарларының диалектында фонетик һәм лексик-грамматик үзенчәлекләрнең тасвирламасы» дигән төп хезмәте зур күләмле монография буларак 1961-1969 елларда дөнья күрде. Ул үзебезнең һәм чит ил тюркологлары тарафыннан югары бәя алды. Мисал өчен, күренекле немец галиме Герхард Дерфер: «Моңа кадәр Көнчыгыш Себер диалекталь төркемен тулаем тасвирлауның булганы юк иде. Менә соңгы вакытта (50-60нчы еллар) бу турыда басмалар күбәйде... Һәм шулар арасында күренекле урынны Д.Тумашева хезмәтләре алып тора...» – дип язды.

Дөрестән дә, моңа кадәр Себер татарлары теле турында В.В.Радловның XIX гасыр башында язылган кайбер фольклор материаллары гына бар иде. 1940 елны, Себер татарларының диалектын өйрәнү максатыннан, бары бер экспедиция оештырыла. Анда галим-фольклорчы Х.Ярми, язучы, соңрак танылган галим Н.Исәнбәт һәм Омск шәһәреннән галим С.Әмиров катнаша.

Диләрә Гариф кызы кабинет галиме булмады. Ул 15 ел дәвамында һәр җәйне, студентлары белән Көнчыгыш Себернең үзәк өлешендәге йөзләрчә авылларда булып, халыкның сөйләм үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнә.

Академик Д.Тумашеваның фәнни планда Себер татарларының телен өйрәнүенең бәхәссез һәм төп нәтиҗәләре Себер татарлары телендә өч диалектны ачыклавыннан, бу диалектларны башка төрки телләр һәм борынгы төрки телләр белән чагыштыруыннан гыйбарәт. Шулай ук аның Себер татарлары теленең әдәби телебезгә мөнәсәбәтен ачыклавы да мөһим фактор булып тора.

# «Ул бәйрәм мәшәкатьләрен яратмый иде…»

**Алия ЗӘЙНУЛЛИНА,**
Көнчыгышны өйрәнү институты студенты

Шушы көннәрдә Казан дөньяның төрле почмакларыннан тюркология өлкәсендә эшләгән галимнәрне үзенә җыя. Шул уңайдан, без филология фәннәре кандидаты, доцент, университетның тюркология кафедрасы мөдире Асия Ризван кызы РӘХИМОВА белән әңгәмә кордык.

**– Асия ханым, университетыбызда Д.Тумашевага багышланган конференция уза. Сезне дә әлеге конференциядә катнаша дип ишеткән идек...**

– Әлбәттә, мин бу конференциядә катнашачакмын. Чыгышымның темасы Диләрә Тумашева өйрәнгән өлкәләрнең берсе – Себер татарлары теле белән бәйле.

**– Белүебезчә, Сез – Диләрә Тумашеваның укучысы. Остазыгызны Мөгаллим һәм Шәхес буларак сурәтләп үтсәгез иде...**

– Диләрә Гариф кызының укучысы булуым белән мин бик горурланам. Остазым таләпчән һәм гадел кеше иде. Беренче нәүбәттә, үзенә карата белде, аның бу сыйфаты безгә дә күчте. Минемчә, Диләрә Тумашева Татарстанның бөек хатын-кыз мөгаллимәсе, ул тюркология фәне үсешенә бәяләп бетергесез өлеш кертте.

**– Сезнең күңелдә остазыгызга бәйле кызыклы фактлар, истәлекләр, хатирәләр дә сакланадыр...**

– Диләрә Тумашева белән бәйле истәлекләр бик күп инде ул. Шуларның берсе хәтергә аеруча да уелып калган. Беркөнне мин остазымнан йөрәгемә якын, ихлас мактау сүзләрен ишеттем. Бу – аның 70 яшьлек юбилеен бәйрәм иткән көне. Дөресен әйтергә кирәк: Диләрә Гарифовна бәйрәм мәшәкатьләрен яратмый иде. Шул көнне ул миңа язып бетерелгән диссертациямнең караламасын укып бетерүе турында әйтте: «Диссертацияң шундый кызыклы, туган көн мәшәкатьләрен читкә куеп, аны бер сулышта укып чыктым», – диде. Бу сүзләр миңа зур мактау булды. Эшемдә шундый уңышларга ирешкәнмен икән, монда, һичшиксез, Диләрә Гариф кызының да өлеше зур. Беренче нәүбәттә, остазыбыз безне эшкә, тел гыйлемен яратырга өйрәтте.




**– Асия ханым, быел бездә – Тукай елы. Тюрколог буларак әйтегез әле: шагыйрь иҗатына республикабызда һәм, аерым алганда, университетта тиешле игътибар биреләме? Әдипнең кайсы әсәрләрен яратасыз? Фәнни-методик эшегездә файдаланасызмы?**

– Тукай – татар әдәбиятының йолдызы. Гомумән, төркидөньяда популяршагыйрь. Конференциягә җыелган галимнәр килешерләр: аның иҗатын «яратам-яратмыйм»га бүлеп булмый. Тукай иҗатын бербөтен буларак кына яратырга мөмкин. Республикабызда Тукай темасы, Тукай әсәрләре киң яңгыраш тапты. Әмма шагыйрьнең башлангыч чор иҗаты, иҗат теле (госманлы төрки тел) ахырга кадәр өйрәнелмәгән. Һәм безнең кафедра бу юнәлешне игътибар үзәгеннән ычкындырмаска тырыша.

**– Сезнең фикерегезчә, студентлар көнделендә Тукай иҗаты нинди урын били?**

– Чынлап әйткәндә, студентлар Тукай иҗатына сирәк мөрәҗәгать итә. Без бу хәлне күпмедер төзәтергә дә тырышабыз инде. Мәсәлән, дәрестә төрекчәгә текст тәрҗемә итәргә кирәк булса, мин Тукай шигырьләрен дә бирәм. Әлбәттә, бу студентларга уйланырга, шагыйрь иҗатының нечкәлекләрен аңларга мөмкинлек бирә.

**– Сезгә һәм конференциядә катнашучыларга зур уңышлар телибез. Әңгәмәгез өчен рәхмәт!**

• Универсиаданы каршылап

# «... ләкин Казан бик олы яшьтә»



**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Татар халкының күренекле галиме Мирфатыйх Зәкиевнең Универсиада кунаклары өчен беренче зур бүләге әзер. Ул – «Татар халкының дөрес тарихы» дигән китап.

Халкыбыз өчен бик әһәмиятле бу хезмәтне Уфа шәһәрендә озак еллар баш архитектор булып эшләгән Мәхмүт Муллаәхмәтов, авторлардан сорап алып, хәзерге көндә үзе җитәкчелек итә торган «Полиграфдизайн» типографиясендә бастыра. Мирфатыйх ага бу китапны язуының максатын менә болай дип аңлатты:





«Казан шәһәрендә узачак Универсиадага бик күп халык килер дип көтелә. Алар татарлар турында, илләрендәге тарих дәреслекләрендә һәм фәнни-популяр әдәбиятларда язылганча, я монгол-татарларның дәвамчылары дип, я тартарлар, ягъни тәмугтан чыгучылар, яки килмешәк, кыргый халык дип беләләр. Универсиада кунакларын безнең республика белән таныштыру программасын әзерләүчеләр татар халкы, Татарстан, Казан һәм башка шәһәрләребезнең тарихы турында дөрес мәгълүматлы булырга тиеш. Хәзерге көндә әле дә экскурсоводлар өчен булган материалларның күбесендә татар халкы, Татарстан һәм Казан шәһәре турындагы тарихи фактлар бозып күрсәтелә. Булачак Универсиада татар халкына гасырлар буена өстендә торган ялган һәм яладан котылу өчен зур мөмкинлек бирә. Гомумдөнья трибунасыннан мәгълүмат чаралары чыганакларында, җәмгыять аңында татар халкы, Казан һәм хәзерге көндә башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез турындагы дөрес тарихны күрсәтү мөмкинлеген кулдан ычкындырсак, бу гафу ителмәслек ялгышлык булачак!»

Мирфатыйх Зәкиевнең тагын бер бүләге бар. Ул – «Казанга ничә яшь?» дип аталачак китап. Әле ул басылу стадиясендә. Барыбыз да беләбез шикелле җавапны... Тик, галим бу сорауга менә нәрсә ди: «Казанның меңъеллыгын без чамалап кына – таштан төзелгән беренче кирмәннәр барлыкка килгән вакыттан санап әйткән идек. Ләкин Казан бик олы яшьтә. Аңа, якынча, 2005-2007 яшьләр чамасы. 2007 елны Рим шәһәренең 2007 еллыгы билгеләп үтелде. Шуна әзерлек барышында табылган тарихи чыганакларда әле Рим төзелә генә башлаган чор истәлекләрендә Казан төбәге турында да мәгълүматлар булуы билгеле...»

• Тәңгә – мунча, җанга – юк

**Римма ИГДЕЕВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

# Хәрби хезмәт кем өчен сынау?

Хәрби хезмәт – егет кешенең Ил алдындагы бурычы. Ул бурычны егет сәламәтлегенә зыян китермичә, нәселенә тап төшермичә үтәргә тиеш.

Өйдән чыгарып җибәргәндә, әти кеше улының кулын кырыс кына кысып: «Улым, нәселебезгә тап төшермә, үз өстеңдәге бурычны намуслы үтә», – дип озата. Әмма бу кырыс әтинең күңелендә ниләр барын беркем дә әйтә алмас, чөнки ул үзе шушы «ут» аша үткән кеше. Ә җебеп төшкән әни, калтыранган куллары белән улына ипи сыныгы каптырып: «Синең кайтуыңны теләп торыр ул, улым, исән-сау әйләнеп кайт!» – дигән сүзләрне яшь тулы күзләре белән ялварып әйтә. Бер читтә оялып кына торган кыз бала: «Мин сине көтәрмен, тик исән-имин әйләнеп кайт», – дип вәгъдә биреп кала. Шул минуттан барысы өчен дә сынау башлана. Бигрәк тә егет белән кызның хисләре сынала.



Күп дус егетләрдән ишеткәнем бар: «Егетне армиядән бары тик бер генә хатын-кыз көтә, ул да булса – әни», – диләр. Алар, бәлки, хаклыдыр да. Мин хәрби хезмәткә егетләрен озаткан күп кызларны беләм. Аларның шактые: «Егетем кайтканчы йөреп калыйм, аннан ул кайткач өйләнешсәк, мин берни дә күрми калам бит. Ә ул барыбер берни белмәячәк», – дигән фикердә йөриләр. «Уеннан уймак чыга» дигән мәкаль бар татар халкында. Шул «йөреп калыйм» вакытында алар, биргән вәгъдәләрен онытып, кияүгә дә чыгып куялар. Ә хәрби хезмәттә йөргән егет йөрәгенә нинди ут салганы турында бик азлары гына уйлана торгандыр.

«Кызы көтмәгәнгә...», «кызы аркасында...» армия хезмәтендә егетләрнең үз-үзләренә кул салган очракларны да ишеткәнем бар. Бер танышымның дусты Чечняга эләккән. Ул һәрвакыт үзенең дустын коткарып кала алмавын сөйли иде. «Көнетөне бомбежка астында ятабыз, бүген-иртәгә өскә төшәр инде, дип һәр көн тормыш белән хушлашабыз. Нервлар какшаган, авыр... Шул сирәк-мирәк килгән хатлар гына күңелне беraз йомшартып, йөрәккә җылы биреп тора. Бервакыт хат алгач, дустымның кәефе кырылганын күрдем. «Ни булды?» – дигәч, ул миңа: «Кызым кияүгә чыга...» – дип җавап бирде. Шул төнне без тагын бомбежка астында калдык. Иптәшем, йөрәге януына түзә алмыйча, үзенә кул салмакчы булды. Коткардым... Әмма икенче төнне ул түзмәгән, янәшәдәге агачка чыгып асылынган. Бу юлы мин алып кала алмадым...» – дип ачынып сөйли иде ул.

«Болай эшләү йомшаклык инде ул, егет кешегә килешми», – диючеләр дә булыр. Әмма нервлары какшаган, көне-төне үлем белән яшәү арасында яткан егетнең рухын сындыру кыен түгел. Руслар әйтмешли, бу бит «масло в огонь». Ә өйдә улларының исән-имин кайтуын көтеп яткан әти белән әни дә бар бит әле... Бу турыда ул уйламаган.

Бу кыйган гамәле белән ул кыз барлык кызларның да намусына тап төшерде. Ә бит вәгъдәләренә тугъры калып, сөйгән ярларын хәрби хезмәттән көтеп алган кызлар да аз түгел. Шулай да мондый хәлләрне күргән егетләре алдында каты сынау үтәргә туры килә.

Хәрби хезмәт егет өчен Ил каршындагы бурычын үтәү булса, кызларга егет алдындагы сынау ул. Биргән вәгъдәнә тугъры калу – ике йөрәк хисләренең сыналуы.

• Халәт

# Татарстан Кыш бабае кайда яши?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Лапландия... Әкияти Лапландия – Санта-Клаус һәм Кар кызы иле. Нәкъ менә шунда Санта-клаус барлык балаларга бүләкләр ясый. Лапландия авылында Санта-Клаусның үз өе, почтасы һәм килгән туристлар белән ял итә торган җире бар. Тирә-якта кар көртләре, чыршылар... Анда барып-кайту өчен, туристлар чиратка язылa... Чынга ашмастай хыяллар дип уйласагыз, нык ялгышасыз! Чөнки безнең үзебезнең Татарстаныбызда да Кыш бабай һәм Кар кызы яши торган бик матур, әкияти җир бар. Кайда соң ул җир, диярсез. Табигате белән Лапландиядән бер дә ким булмаган урында ул. Барыбызга да таныш Арча районы Яңа Кырлай авылының чыршы урманы эчендә һәм Ия елгасы кырыенда Кыш бабай һәм Кар кызы сарайчыгы бар (Габдулла Тукай исемендәге дәүләт музее базасында). 2009 елдан бирле бу җирләр, кыш җиту белән, сихри, әкияти урыннарның берсенә әверелә. 2009 елда иң бәхетле 750 кешегә Кыш бабай һәм Кар кызы янәшәсендә күңел ачарга насыйп булган. Ә узган елны исә, Татарстаннан гына түгел, Түбән Новгород, Мәскәү, Самара, Чиләбе, Орлов өлкәләреннән 2500гә якын кеше кышкы каникулларын нәкъ менә Татарстан «лапландиясенә» сәяхәткә килеп үткәргән! Алдагы елларда чыршы урманында Кыш бабай, Кар кызы белән күңел ачу, җырлапбиеп, атларда йөреп, төрле әкияти геройларның әкәмәтләрен карап, чанаçаңгыларда шусалар, быел кунып калу мөмкинлеге дә була. Чөнки 1 декабрьдән туристлар өчен 48 урынга исәпләнгән кунакханә ачылачак. Икенче катта Кыш бабайның үз йокы бүлмәсе дә булачак.



Традиция буенча, 18 декабрьдә Кыш бабай үзенең Кышкы аланлыгына килә һәм бер ай буе килгән кунакларны үзенең бүләкләре, ачык йөзе белән шатландыра. Быел Кыш бабай һәм Кар кызы янына 6 меңнән артык турист килер дип көтелә. Шуна күрә чаралар да бик кызыклы һәм үзенчәлекле итеп планлаштырыла. Оештыручылар әйтүенчә, программаның максаты ниндидер табыш китерүгә генә корылмаган, ә, бәлки, татарстанлыларны һәм килачәк кунакларны үзебезнең татар мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштырудан гыйбарәт. Моннан тыш, әкияти геройларның Габдулла Тукай әсәрләреннән алынуы да зур әһәмияткә ия. Чөнки бу геройлар безнең милләтнең горурлыгы, йөзе. Чит илдәге Белоснежка, гномнар, Микки Маус, Дональд Даглар янәшәсенә куярлык Шүрәлебез, Су анасы, Убырлы карчык, Батыр, Алтынчәч, Таһир-Зөһрәләребез барлыгын тагын бер кат искәртү йөзеннән, Чыршы урманында үзебезнең татар персонажлары булачак. Бу геройларны мин татарларның брендлы дип тә атар идем әле. Оештыручылар искәртеп узганча, нәкъ менә шушы әкият геройларыбыз туристларны Кыш бабай янына чакырып китерә дә инде.

Әйтеп үткәнемчә, монда килгән кеше үзенә бер елга җитәрлек энергия һәм яхшы кәеф алып китә. Ачык һавада, урман эчендә дусларың, якыннарың белән ял итүгә ни җитә! Кунакханә, татар милли ризыклары өстенлек иткән ресторан, Кыш бабай һәм Кар кызының Яңа ел бүләкләре... Йә, әйдәгез, киттекме Кыш бабай янына?

***P.S.** Сүз уңаеннан, 25 октябрьгә кадәр **Кыш бабай ролен** бик яхшы итеп үти алырдай егетләрдән (20 яшьтән алып) гаризалар кабул ителә. 5 ноябрьдә конкурска нәтиҗә ясалачак. Бу рольгә лаек дип табылган кеше, Вологда өлкәсенең Бөек Устюг шәһәрчегенә иң төп Кыш бабай янына кунакка барып, «абыйсы»ның фатихасын алыр дип көтелә. Гаризалар **tat.tourism@tatar.ru** электрон адресына кабул ителә. Конкурсның шартлары: Кыш бабайның татар һәм рус телләрен камил белүе, шук-шаян, аралашучан булуы, балалар белән эшли алуы.*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999
Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла